КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 14 сентябрь г.Казань № 871

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында

Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән 16+200 км – 21+977 км» автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Кощаково авыл җирлеге адресы буенча урнашкан, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр категориясендәге 38 906 кв.метр мәйданлы һәм 16:33:080710:333 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган, М.З.Хәйруллин милкендә булган (алга таба – алына торган җир кишәрлеге милекчесе) 527 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге) Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Бу декарарга теркәлгән 16:33:080710:333 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 527 кв.метр мәйданлы җир кишәрлеге урнашу схемасын расларга.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районындагы Кощаково авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлеге милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен каплау күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлеге өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлегенә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлеге милекчесе тарафыннан имзаланган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта бирелмәгән очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

4. Татарстанның юл-транспорт идарәсенә 16:33:080710:333 кадастр санлы җир кишәрлегенә һәм алына торган җир кишәрлегенә карата кадастр эшләрен бу карар белән расланган урнашу схемасы нигезендә үткәрүне тәэмин итәргә.


5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 14 сентябрь, 871 нче
карары белән расланды

16:33:080710:333 кадастр санлы җир кишәрлегеннән барлыкка килә торган 527 кв.метр мәйданлы җир кишәрлегенең урнашу схемасы

| Җир кишәрлегенең шартлы номеры – :3641:ЗУ1 | | |
|---|---|---|
| Җир кишәрлегенең мәйданы – 527 кв.м | | |
| Координатлар системасы – МСК-16 | | |
| Чикләрнең характерлы нокталарын билгеләү | Координатлар, м | |
| | X | У |
| н1 | 477022.26 | 1320133.24 |
| н2 | 477065.54 | 1320236.11 |
| н3 | 477056.30 | 1320238.50 |
| н1 | 477022.26 | 1320133.24 |




Масштабы 1:500

Шартлы билгеләр:

16:33:080710:333 – чыганак җир кишәрлегенең кадастр саны;

:333:ЗУ1 – барлыкка килә торган җир кишәрлеге билгесе;

– чыганак җир кишәрлеге билгесе;

– җир кишәрлекләре чикләре билгесе;

– кадастр кварталы чикләре билгесе;

– территориядән махсус файдалану шартлары булган зона билгесе;

16:33:080710 – кадастр кварталы билгесе;

н1 – урнашу урынын билгеләү өчен мәгълүматлары җитәрлек булган чикнең характерлы ноктасы билгесе;

– юл өчен даими бүлеп бирелгән полоса чиге;

– урнашу урынын билгеләү өчен мәгълүматлары җитәрлек булган чикнең яңадан барлыкка килгән өлеше